СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за “Мамадышский”,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мира ур., 11А нче йорт, “Мамадыш” совхозы поселогы, Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

“28” марта 2023 г. — №4-22

Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советының 2020 елның 19 февралендәге 4-50 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12[1] статьясының 4[2] өлеше һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 8 өлеше, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советы

к а р а р  к а б у л  и т т е:

1. Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советының 2020 елның 19 февралендәге «Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 4-50 номерлы карарының үз көчен югалтуын танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге каранның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы В.А.Гиззатуллинага йөкләргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Кызыл Тау
авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе /В.А.Гиззатуллина/

СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ